| | |
|---|---|
| **МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ** |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

04.10.2016 № 568

г.Казань

Боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2016 елның 26 октябрендә теркәлде, № 3538

Инвалид бала өчен сатып алынган
товарның барлыгын тикшерү
актын гражданнарга бирү тәртибе турында

“Балалы гаиләләргә дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында” 2006 елның 29 декабрендәге № 256-ФЗ Федераль законның 11.1 маддәсен, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 30 апрелендәге "Инвалид балаларны социаль яраклаштыру һәм җәмгыятькә кертеп җибәрү өчен билгеләнгән товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алуга чыгымнарны компенсацияләү юлы белән, ана (гаилә) капиталы акчасын (акчаның бер өлешен) андый товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрне сатып алуга юллау кагыйдәләре турында" № 380 карарын, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2016 елның 16 июнендәге "Гражданнарның ана (гаилә) капиталы акчасын, инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасына туры китереп, инвалид балаларны социаль яраклаштыру һәм җәмгыятькә кертеп җибәрү өчен билгеләнгән товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алуга файдалану хокукларын тормышка ашыруны тәэмин итү буенча эшне оештыру турында" № 296 боерыгын гамәлгә ашыру кысасында боерык бирәм:

1. Инвалид бала өчен сатып алынган товарның барлыгын тикшерү актын гражданнарга бирүнең кушымта итеп бирелүче тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) инвалидлар белән эшләү бүлеге һәм социаль хезмәт күрсәтү бүлеге башлыкларына: бу боерык белән расланган Тәртипне гамәлгә ашырганда, Министрлыкның Татарстан Республикасы муниципаль районнарындагы (шәһәр округларындагы) идарәләренә (бүлекләренә) (алга таба – социаль яклауның территориаль органнары) оештыру-методология ярдәмен күрсәтергә.

3. Социаль яклауның территориаль органнары башлыкларына: бу боерык белән расланган Тәртипкә туры китереп, Инвалид бала өчен сатып алынган товарның барлыгын тикшерү актын гражданнарга бирүне тәэмин итәргә.

4. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрының Министрлыкның бу боерыкның 2 пунктында күрсәтелгән бүлекләре өчен җаваплы урынбасарларына йөкләргә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2016 елның 4 октябрендәге № 568 боерыгы белән расланды

**Инвалид бала өчен сатып алынган товарның барлыгын тикшерү актын гражданнарга бирү тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Инвалид бала өчен сатып алынган товарның барлыгын тикшерү актын гражданнарга бирүнең бу тәртибе (алга таба – Тәртип) “Балалы гаиләләргә дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында” 2006 елның 29 декабрендәге № 256-ФЗ Федераль законның 11.1 маддәсен, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 30 апрелендәге "Инвалид балаларны социаль яраклаштыру һәм җәмгыятькә кертеп җибәрү өчен билгеләнгән товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алуга чыгымнарны компенсацияләү юлы белән, ана (гаилә) капиталы акчасын (акчаның бер өлешен) андый товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрне сатып алуга юллау кагыйдәләре, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 31 июлендәге “Медик-социаль экспертиза федераль дәүләт учреждениесе тарафыннан бирелүче: инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасын, инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасын һәм аларның формаларын булдыру һәм тормышка ашыру тәртибен раслау турында” № 528н боерыгын, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2016 елның 16 июнендәге “Гражданнарның ана (гаилә) капиталы акчасын, инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасына туры китереп, инвалид балаларны социаль яраклаштыру һәм җәмгыятькә кертеп җибәрү өчен билгеләнгән товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алуга файдалану хокукларын тормышка ашыруны тәэмин итү буенча эшне оештыру турында” № 296 боерыгын гамәлгә ашыру максатыннан эшләнде һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районнарындагы (шәһәр округларындагы) идарәләренең (бүлекләренең) (алга таба – социаль яклауның территориаль органы) Инвалид бала өчен сатып алынган, инвалид балаларны социаль яраклаштыру һәм җәмгыятькә кертеп җибәрү өчен билгеләнгән товарның барлыгын тикшерү актын (алга таба – тикшерү акты) гражданнарга бирү тәртибен билгели.

1.2. Бу Тәртиптә төшенчәләр һәм терминнар 2013 елның 28 декабрендәге “Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында” № 442-ФЗ Федераль закон, “Балалы гаиләләргә дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында” 2006 елның 29 декабрендәге № 256-ФЗ Федераль закон билгеләгән мәгънәләрдә файдаланыла.

1.3. Тикшерү актын төзегәндә һәм аны биргәндә, Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләренең социаль хезмәтне өйдә күрсәтү бүлекләре катнаша.

## 2. Инвалид бала өчен сатып алынган товарның барлыгын тикшерү актын бирү турында гаризаны кабул итү һәм теркәү

2.1. Ана (гаилә) капиталына сертификатның хуҗасы (алга таба – гражданин) яки аның законлы вәкиле яисә гражданин вәкаләт биргән зат социаль яклауның яшәү урынындагы яки вакытлыча булу урынындагы (алга таба – яшәү урыны) территориаль органына тикшерү актын бирү турында бу Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендәге форма буенча язмача яки электрон рәвештә гариза (алга таба – гариза) тапшыра. Гаризада инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасы күздә тоткан берничә товар күрсәтелергә мөмкин.

Гариза гражданин яки аның законлы вәкиле яисә гражданин вәкаләт биргән зат социаль яклауның яшәү урынындагы территориаль органына шәхсән мөрәҗәгать итеп тапшырылырга яки почта элемтәсе оешмалары аша кәгазьдә яисә "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәреннән файдаланып, 2011 елның 6 апрелендәге "Электрон имза турында" № 63-ФЗ Федераль закон һәм 2010 елның 27 июлендәге "Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтүне оештыру турында" № 210-ФЗ Федераль закон таләпләренә туры китереп, электрон имза белән имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендә җибәрелергә мөмкин.

Гариза тапшырганда, гражданин шәхесен таныклаучы документ күрсәтә. Гариза гражданин вәкаләт биргән зат яки аның законлы вәкиле тарафыннан тапшырылган очракта, шәхесен таныклаучы документ һәм гражданинның мәнфәгатьләрен чагылдыруга вәкаләтен раслаучы документ күрсәтелә.

Гаризаны почта элемтәсе оешмалары аша җибәргәндә, гаризага кушып, гражданин вәкаләт биргән затның яки гражданинның законлы вәкиленең гражданинның мәнфәгатьләрен чагылдыруга вәкаләтен раслаучы документларның Россия Федерациясе законнарына туры китереп расланган күчермәләре җибәрелә.

2.2. Социаль яклауның территориаль органы хезмәткәре гаризаны кабул итә һәм аны тикшерү актын бирү турындагы гаризаларны теркәүнең бу Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендәге форма буенча алып барыла торган журналында терки:

шәхсән кабул иткәндә – гражданин яки гражданинның законлы вәкиле яисә гражданин вәкаләт биргән зат социаль яклауның территориаль органына гариза белән мөрәҗәгать иткән көнне;

гариза почта элемтәсе оешмалары аша яки электрон документлар рәвешендә кергәндә – гариза социаль яклауның территориаль органына кергән көнне яисә, гариза социаль яклауның территориаль органының эш көне тәмамлангач кергән очракта, икенче көнне; гариза электрон документлар рәвешендә ял яки эшләми торган бәйрәм көннәрендә кергән очракта, ял яки эшләми торган бәйрәм көннән соң килүче эш көнендә.

2.3. Социаль яклауның территориаль органы, халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзегенең социаль хезмәтне өйдә күрсәтү бүлеге хезмәткәре тикшерү

актын төзү буенча әзерлек эшен башкарсын өчен, теркәлгән гаризаның күчермәсен, аны теркәгән көннән алып бер эш көне эчендә, Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәгенә җибәрә.

## 3. Инвалид бала өчен сатып алынган товарның барлыгын тикшерү актын төзү һәм бирү

3.1. Халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәгенең социаль хезмәтне өйдә күрсәтү бүлеге хезмәткәре, гариза теркәлгән көннән алып ике эш көненнән артмаган срокта, гаризада күрсәтелгән ысул белән, халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәгенең эш көннәрендә һәм эш вакытында, тикшерү актын төзү һәм бирү өчен, инвалид баланың гаризада күрсәтелгән яшәү урынындагы гаиләгә килү көне һәм вакыты турында гражданинга яки аның законлы вәкиленә мәгълүмат җиткерә.

3.2. Тикшерү акты гариза теркәлгән көннән алып биш эш көненнән соңга калмыйча, халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәгенең социаль хезмәтне өйдә күрсәтү бүлеге хезмәткәре һәм социаль яклауның территориаль органы җитәкчесе белән берлектә, гражданин яки аның законлы вәкиле күрсәткән документлар (алар турында мәгълүмат тикшерү актында күрсәтелә), шулай ук инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең товар сатып алынган көндә гамәлдә булган индивидуаль программасы (“Медик-социаль экспертизаның Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча баш бюросы” ФКУ тарафыннан бирелгән) һәм барлыгы тикшерелә торган товарның сатып алынуын раслаучы документлар нигезендә инвалид баланың яшәү урынында төзелә.

Инвалид бала өчен сатып алынган товарның барлыгын тикшерү нәтиҗәләре Россия Федерациясе Пенсия фонды киңәшләрен исәпкә алып, бу Тәртипкә 3 нче кушымта нигезендәге форма буенча ике нөсхәдә төзелгән тикшерү актына теркәп куела. Нөсхәләр социаль яклауның территориаль органы җитәкчесе, халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәгенең социаль хезмәтне өйдә күрсәтү бүлеге хезмәткәре һәм гражданин яки аның законлы вәкиле тарафыннан имзалана.

Тикшерү актында сатып алынган товарның Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 30 апрелендәге № 831-р әмере белән расланган: инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасының “Инвалид балаларны социаль яраклаштыру һәм җәмгыятькә кертеп җибәрү өчен билгеләнгән, ана (гаилә) капиталы акчасы (акчаның бер өлеше) аларны сатып алуга юллана торган товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр” бүлегендә күрсәтелгән товар атамасына һәм Инвалид балаларны социаль яраклаштыру һәм җәмгыятькә кертеп җибәрү өчен билгеләнгән товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр исемлегенә тәңгәл килүе (тәңгәл килмәве) күрсәтелә.

Гражданин яки аның законлы вәкиле әлеге актны имзалаудан баш тарткан очракта, бу хакта анда тиешле язма ясала.

3.3. Тикшерү актының бер нөсхәсе, аны төзегән көнне, социаль яклауның территориаль органы җитәкчесе тарафыннан, гражданинга Россия Федерациясе Пенсия фондына тапшыру өчен бирелә.

Тикшерү актының икенче нөсхәсе белән гариза социаль яклауның территориаль органында, архив законнарының һәм 2006 елның 27 июлендәге “Персональ мәгълүматлар турында” № 152-ФЗ Федераль закон нигезләмәләренә туры китереп, тикшерү актларын бирүне исәпкә алу папкасында, саклау срокларын күрсәтеп, Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының 2010 елның 25 августындагы № 558 боерыгы белән расланган Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар эшчәнлеге процессында барлыкка килүче, идарә итү буенча типовой архив документлары исемлегенең 183 пунктындагы “б” пунктчасы нигезендә биш ел дәвамында саклана.

Тикшерү акты ике ягына да язылган бер биттә урнаша һәм инвалид бала өчен сатып алынган – инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасында күрсәтелгән һәр товарга аерым рәсмиләштерелә.

Инвалид бала өчен сатып алынган
товарның барлыгын тикшерү актын
гражданнарга бирү тәртибенә
1 нче кушымта

*Форма*

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны
эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгының территориаль органына

**Инвалид бала өчен сатып алынган товарның[1] барлыгын тикшерү актын бирү турында гариза**

______________________________________________________________________
(ана (гаилә) капиталына дәүләт сертификаты хуҗасының фамилиясе, исеме, атасының исеме)

______________________________________________________________________
(ана (гаилә) капиталына дәүләт сертификаты хуҗасының законлы вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)

1. Гариза бирүченең – сертификат хуҗасының/аның законлы вәкиленең шәхесен таныклаучы документ (кирәклесенең астына сызарга)

______________________________________________________________________
(документның атамасы, номеры һәм сериясе, кем тарафыннан һәм кайчан бирелүе)
______________________________________________________________________

2. Инвалид бала турында мәгълүматлар ______________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме,
______________________________________________________________________
туган көне, ае, елы)

3. Инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасының номерын һәм көнен күрсәтеп, сатып алынган товарның атамасы: ______________________
______________________________________________________________________

4. Гариза бирүченең элемтәгә керү өчен телефоны һәм инвалид баланың яшәү урыны адресы:
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

5. Инвалид бала өчен сатып алынган товарның барлыгын тикшерү өчен гаиләгә килү көне һәм вакыты турында мәгълүматны алырга риза: ______________________________
(язмача, телефоннан, смс-хәбәр итеп, электрон почта аша)
(кирәклесенең астына сызарга һәм күрсәтергә)

| | |
|---|---|
| "___" __________ 20___ ел | __________ ____________________<br>(имза) (тулы имза Фамилия, инициаллар) |

[1] Товар инвалид балаларны социаль яраклаштыру һәм җәмгыятькә кертеп җибәрү өчен билгеләнгән.

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -
(кисеп алу сызыгы)

| | |
|---|---|
| Инвалид бала өчен сатып алынган товарның барлыгын тикшерү актын бирү турында гариза кабул ителде һәм теркәлде:<br>№ _______ "____" ___________ 20 ___ ел. | Кабул итте:<br><br>__________ ____________________<br>(белгеч имзасы) (хезмәткәрнең ФИО, телефоны) |

Инвалид бала өчен сатып алынган товарның барлыгын тикшерү актын гражданнарга бирү тәртибенә
2 нче кушымта

*Форма*

**20___ елда инвалид бала өчен сатып алынган товарның[1] барлыгын тикшерү актын бирү турында гаризаларны теркәү**

**ЖУРНАЛЫ[2]**

| Т-п № | Гаризаны теркәү көне һәм вакыты | Гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме | Мөрәҗәгать итү формасы (почта, эл. почта, шәхсән) | Гаризаны теркәгән белгечнең фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм имзасы | Социаль яклауның комплекслы үзәгенә тапшыру көне һәм вакыты | Тикшерү актын бирү көне һәм номеры |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 1. | | | | | | |
| 2. | | | | | | |
| 3. | | | | | | |
| … | | | | | | |

1 Журнал төпләнә, номерлана һәм мөһер белән ныгытыла. Исәпкә алу журналының битләр саны соңгы биттә социаль яклауның территориаль органы начальнигы (җитәкчесе) имзасы белән раслана.

2 Товар инвалид балаларны социаль яраклаштыру һәм җәмгыятькә кертеп җибәрү өчен билгеләнгән

Инвалид бала өчен сатып алынган
товарның барлыгын тикшерү актын
гражданнарга бирү тәртибенә
3 нче кушымта

*Форма*

**Инвалид бала өчен сатып алынган товарның[1] барлыгын тикшерү**

**АКТы**

№ ________ “____” __________ 20_____ ел

______________________________________________________________________________
(ана (гаилә) капиталына дәүләт сертификаты хуҗасының фамилиясе, исеме, атасының исеме)

1. Шәхесне таныклаучы документ ______________________________________________
(атамасы,
______________________________________________________________________________
номеры һәм сериясе, кем тарафыннан һәм кайчан бирелүе)

2. СНИЛС ______________________________________________________________________

3. Инвалид бала турында мәгълүматлар ___________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме,
______________________________________________________________________________
туган көне, ае, елы)

4. Сатып алынган товар турында мәгълүмат:
4.1. Сатып алынган товарның атамасы ___________________________________________
______________________________________________________________________________

| 4.2. | Товар бар | | | Товар юк | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | (туры килә торганы галка белән билгеләнә) | | | | | | |

| 4.3. | Товар[2]: | | |
|---|---|---|---|
| | Инвалид балаларны социаль яраклаштыру һәм җәмгыятькә кертеп җибәрү өчен билгеләнгән товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрнең Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 30 апрелендәге № 831-р әмере белән расланган исемлегендәге атамасы | Россия Федерациясенең Техник җайга салу һәм метрология агентлыгының 2014 елның 23 сентябрендәге № 1177-ст боерыгы белән расланган “Тормыш алып барулары чикләнгән кешеләр өчен ярдәмче әйберләр. Классификацияләре һәм терминнары” ГОСТ Р ИСО 9999-2014 илкүләм стандартына туры килә торган коды | |
| | | | |

| Товар тәңгәл килә | | Товар тәңгәл килми | |
|---|---|---|---|
| (туры килә торганы галка белән билгеләнә) | | | |

---

[1] Товар инвалид балаларны социаль яраклаштыру һәм җәмгыятькә кертеп җибәрү өчен билгеләнгән. Инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасындагы “Инвалид балаларны социаль яраклаштыру һәм җәмгыятькә кертеп җибәрү өчен билгеләнгән, ана (гаилә) капиталы акчасы (акчаның бер өлеше) аларны сатып алуга юллана торган товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр” дигән бүлектә күрсәтелгән.

[2] Таблицада товарның атамасы һәм инвалид бала өчен сатып алынучы товарның илкүләм стандарты коды күрсәтелә.

| | |
|---|---|
| | |

4.4. Инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең

______________________________________________________________ тарафыннан бирелгән

(медик-социаль экспертиза федераль дәүләт учреждениесе атамасы)

индивидуаль программасында күрсәтелгән товарлар исемлегенә

______________________________________________________________

(Инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасы номеры һәм гамәлдә булу срогы)

______________________________________________________________

(медик-социаль экспертиза уздыру беркетмәсенең номеры, числосы, ае, елы)

| Товар тәңгәл килә | | Товар тәңгәл килми | |
|---|---|---|---|
| (туры килә торганы галка белән билгеләнә) | | | |

| | | |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклауның территориаль органы җитәкчесе | ______________<br>(имза)<br><br>М.У.<br>(мөһер урыны) | ______________<br>(тулы имза<br>Фамилия, инициаллар)<br>“____” ___________ 20___ ел<br>(дата) |
| | | |
| “Тикшерү актында күрсәтелгән мәгълүматлар тапшырылган документларга туры килә”: | | |
| Халыкка социаль ярдәм күрсәтү комплексы үзәгенең социаль хезмәтне өйдә күрсәтү бүлеге хезмәткәре | ______________<br>(имза) | ______________<br>(тулы имза<br>Фамилия, инициаллар)<br>“____” ___________ 20___ ел<br>(дата) |
| Ана (гаилә) капиталына дәүләт сертификаты хуҗасы/аның законлы вәкиле | ______________<br>(имза) | ______________<br>(тулы имза<br>Фамилия, инициаллар)<br>“____” ___________ 20___ ел<br>(дата) |